Совет Старочукалинского сельского поселения Дрожжановского муниципального Республики Татарстан

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалырайона авыл җирлеге Советы

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12

==========================================================

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Иске Чокалы авылы

26 июль 2023 ел № 28/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлеге Уставының 32 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлегендә Иске Чокалы авыл җирлеге Советының 06.06.2022 ел, № 17/1 карары ( 16.12.2022 ел, №22/3,16.02.2023ел №24/2 редакциясендә) белән расланган Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**26 нчы маддәнең икенче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“- бюджет һәм акча йөкләмәләрен кабул итү һәм исәпкә алу;";

**21 нчы маддәнең 24 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:**

« Бюджет проектын төзү:

Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәте таләпләрен) билгеләүче Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Җыенына юлламасы нигезләмәләренә;

Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча иҗтимагый хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгеләүче документларга;

Россия Федерациясенең Бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләренә (Россия Федерациясе субъектларының бюджет һәм салым

сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекләрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

социаль-икътисади үсеш фаразларына;

бюджет прогнозы (бюджет прогнозы проекты, бюджет прогнозы үзгәрешләре проекты) озак вакытлы чорга;

дәүләт (муниципаль) программаларында (дәүләт (муниципаль) программалары проектларында, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектларында)нигезләнә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Чокалы авыл
җирлеге Башлыгы: Р.Р.Низамутдинов